ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«  9  »   07    2025 ел**

**КАРАР**
**№   168**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район Башлыгы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча Чепья авыл җирлеге халкы катнашында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы Р. С. Фатыйхов;

- пространство белешмәләре фонды ДБУ (ГБУ фонд пространственных данных) вәкиле.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын билгеләргә - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр итү вакытыннан башлап. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан артык була алмый.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки  Татарстан Республикасы

Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль район башлыгы Р. Р. Нотфуллин